

Мордовиянен Большеберезники районында 29 апрельдә ачылган «Сурский рубеж» мемориаль комплексы  инде әһәмиятле ижтимагый хәрби-тарихи һәм патриотик проектларны җәлеп итv урынына әйләнде. Бу хакта тобәк массакvләм мәгълvмат чаралары вәкилләренә И.Д.Воронин исемендәге Туган якны ойрәнv музеенда узган брифингта сойләделәр.
Очрашуда «Сурский рубеж» телеграм-каналын тәкъдир иттеләр һәм быел әлеге һәйкәл һәм тарихи мирасны саклау белән бәйле барлык планлаштырылган вакыйгалар турында сойләделәр.

Һәйкәлләр мәдәни тәнгәллекне саклауда топ роль уйныйлар һәм киләчәк буыннарга vткәннәр турындагы белемнәрне тапшыралар. Шул ук вакытта объектларны торгызу һәм ачу гына тvгел, җәмгыятьнен аларга карата кызыксынуын кvтәрv дә моһим.
Мордовиянен Мәдәният, милли сәясәт һәм архив эше министры Светлана Баулина сойләвенчә, республиканын архивларында, музейларында һәм фәнни-тикшеренv институтында, кешеләр, бигрәк тә яшьләр тарихка кагылсын очен, мәгълvмат җыю буенча зур эш башкарылган.
Светлана Баулина «Сурский рубеж» мемориаль комплексы ел әйләнәсе узачак чаралар турында да сойләде.
- Безнен беренче чираттагы бурыч - мәгълvматлар банкын җыю һәм Сура рубежы тозелешенен беренче истәлек китабын кәгазь һәм электрон рәвештә бастыру, - дип ассызыклады Светлана Баулина.
- Мемориалда билгеләп vтеләчәк истәлекле даталарнын аерылгысыз ритуалы булып Хәтер вахтасы һәм Мактаукаравыл хезмәте кую булачак,- дип билгеләп vтте яшьләр эшләре буенча Дәvләт комитеты рәисе Анастасия Гришнева.
- Сура чиге башка тобәкләрне дә колачлады - Пенза, Ульяновск олкәсе, Чувашия. Без анда чик тозелешенә катнашы булган кешеләрнен һәм аларнын токымнарынын дәлилләрен җыю буенча эш алып бара башладык,- дип уртаклашты Мордва халкынын тобәкара ижтимагый оешмасы рәисе Юрий Мишанин.
Мордовиядәге хәрби-тарихи җәмгыять рәисе, РМ Хокvмәте каршындагы гуманитар фәннәр фәнни-тикшеренv институты директоры Галина Куршева Дәvләт vзәк архивы белән берлектә алып барылган эш белән таныштырды. Галина Куршева билгеләп vткәнчә, хәзер Мордовиядә Сура рубежын тозv турындагы документлар, шигырьләр һәм истәлекләр җыентыгы (альбом) бастыруга әзерләнә. Бу эш РМ башлыгы Артем Здунов һәм РМ Хокvмәте ярдәме белән алып барыла.
Сура чиге турындагы истәлек безнен йорәкләрдә һәм киләчәк буыннарыбыз йорәкләрендә халкыбызнын какшамаслыгы һәм ныклыгы символы буларак яшәячәк.

**Наилә НАСЫРОВА**